**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22 chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

# КАРАРЫ

**2015 елның «16» октябреннән** **№ 2-9**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 21 июлендәге 59 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы,

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»на түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 6 статьясына түбәндәге эчтәлекле 38 пунктны өстәргә: «муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;»;
- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 6 статьясындагы 15 пунктында» «көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызлау, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу» сүзләренә алмаштырырга;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 6 статьясындагы 16 пунктында, 48 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында «шул исәптән сатып алу юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына «җирлектә яшәүчеләргә массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле үтемлелеген тәэмин итү.» сүзләрен өстәргә;

– «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясындагы 1 өлеше 3 пунктына «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221 – ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм Территория картасы-планын раслау.» сүзләрен ӧстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына «җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;» сүзләрен өстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясының 1 өлеше 5 пунктына «җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;» сүзләрен өстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясының 1 өлеше 57 пунктында «муниципаль район территориясендә яшәүче милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, милли азчылык хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны эшкәртә һәм тормышка ашыра;» сүзләрен «чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән;» сүзләренә алмаштырырга;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»ның 48 статьясындагы 2 өлешенә «җирлек территориясендә яшәүче күзәтчелексез хайваннарны тоту һәм тоту чараларын гамәлгә ашыру.» сүзләрен өстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы»ның 73 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә: «муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә исәпкә алына.»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы»ның 83 статьясын 16 пунктындагы «Район бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга тиеш» сүзләрен «Җирле бюджет проектын, җирле бюджетны раслау турындагы карарны, аның үтәлеше турындагы еллык хисапны, җирле бюджет үтәлеше турында квартал саен белешмәләрне һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турындагы мәгълүмат җирле бюджет проектына, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү чыгымнарын күрсәтеп рәсми басылып чыгарга тиеш. Җирле үзидарә органнары җирлектә яшәүчеләргә әлеге документлар һәм белешмәләр белән аларны бастырып чыгара алмаган очракта танышу мөмкинлеген тәэмин итә» ( үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы»на 1 нче кушымта.). .

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» игълан итәргә (бастырырга).

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**